## Эшне үтәү буенча кулланма

Татар теленнән белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора.

Беренче өлеш 12 биремне үз эченә ала (А1-А12), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган җавапны сайлап алырга тиеш.

Икенче өлеш В1-В6 биремнәреннән тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. В1-В6 биремнәренә җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиешсез.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыкса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз. Беренче өлештәге биремнәргә якынча 2 минут вакыт бирелә. Икенче өлештәге һәр биремгә 3-4 минут вакытыгызны сарыф итегез.

Дөрес җаваплар, катлаулылыкларыннан чыгып, 1 яки югарырак баллар белән бәяләнәләр. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, сезгә гомуми балл чыгарыла, шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез !**

**1 вариант**

**1 өлеш (А)**

***Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А12) үтәгәндә, җавалар бланкында эшләнә торган бирем аста урнашкан, дөрес дип табылган җавап номеры шакмагына «Х» билгесе куегыз.***

**А1. Нечкә сузыклардан торган рәтне табыгыз.**

1. [ө], [и], [ә], [ү], [о]
2. [ә], [ү], [ө], [э (е)], [и]
3. [ә], [й], [ө], [э (е)],] [и]
4. [ү], [ө], [ә], [и], [й]

**А2. Яңгырау булмаган авазны табыгыз.**

1. [х]
2. [з]
3. [р]
4. [л]

**А3. Хаталы сүзе булган рәтне табыгыз.**

1. җимеш, һәйкәл, хәм, тамчы
2. волейбол, завод, пароход, витамин
3. зирәк, хат, җиләк, маңгай
4. телевизор, мотоцикл, вагон, щи

**А4. Кайсы рәттәге сүзләрдә ъ хәрефе языла?**

1. көн...як, төн...як, пул...с
2. бер...юлы, бер...яклы, бер...еллык
3. кул...яулык, ар...як, кул...югыч
4. биш...еллык, тигез...яклы, гам...сез

**А5. Күплек сандагы исемнәрдән торган рәтне табыгыз.**

1. укыйлар, язалар, саныйлар
2. үләннәр, куяннар, килгәннәр
3. керпеләр, аюлар, еланнар
4. матурлар, зурлар, акыллылар

**A6.** *Эш* **сүзенә тамырдаш сүзләрдән генә торган рәтне табыгыз.**

1. эшли, эшче, эшне
2. эшлекле, эшче, эшчәнлек
3. эшкә, эшли, эшче
4. эшнең, эшкә, эшен

**A7.** *Савыт-саба* **сүзенең ясалышын билгеләгез.**

1. ясалма
2. тезмә
3. парлы
4. кушма

**A8. Бирелгән мәкальдә күп нокталар урынына кайсы кушымчалар ялгана?**

*Аяг... кыек булса да, юл... туры булсын.*

1. –ның
2. – ың
3. – ка
4. – ны

**A9.** *Кызыл* **сыйфатының артыклык дәрәҗәсен табыгыз.**

1. кызгылт
2. кып-кызыл
3. кызылрак
4. ал

**A10.** *Син* **алмашлыгының төшем килешендә төрләнешен табыгыз.**

1. син
2. синнән
3. сине
4. синең

**A11. Төшеп калган сүзне табыгыз.**

*“Фигыльләр ... белән төрләнмиләр”.*

1. зат-сан
2. заман

3. барлык-юклык
4. килеш

**А12. Тәртип саннарының кушымчаларын табыгыз.**

1. – лар, –ләр, –нар, –нәр
2. –ынчы, –енче, –нчы, –нче
3. – лык, –лек,– лы, –ле
4. – чы, – че, –гыч, –геч

**2 өлеш (В)**

***Әлеге өлештәге биремнәрне, тәкъдим ителгән текст ярдәмендә үтәгәндә, җавапларыгызны җавап бланкында В1-В6 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга ярамый.***

(1) Сызылып таң атты. (2) Каракош сырты артыннан кып-кызыл кояш күтәрелде. (3) Күк йөзе ак төс алды.(4) Һава суытып җибәрде. (Г. Галиев)

**В1.** 3 нче җөмләдәге сыйфатның антонимын языгыз.

**В2.** 2 нче җөмләдәге кушма сүзне табыгыз.

**В3.** 2 нче җөмләдәге сыйфатны языгыз.

**В4.** 1 нче җөмләдән юлдан-юлга күчерергә мөмкин булмаган сүзне язып алыгыз.

**В5.** 4 нче җөмләдәге калын сузыклардан торган исемне төшем килешенә куеп языгыз.

**В6.** 4 нче җөмләдән [w] авазы булган сүзне язып алыгыз.